**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әлкәй авыл җирлеге Советы**
# КАРАРЫ

Әлкәй авылы № 21 15 март 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 97 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (2015 елның 14 августындагы №120, 2015 елның 29 октябрендәге 13 номерлы, 2018 елның 24 апрелендәге 93 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 116 номерлы, 2018 елның 24 декабрендәге 121, 2019 елның 24 июнендәге 139 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 153 номерлы карарлар редакциясендә)

"Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 23 ноябрендәге 374-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Әлкәй авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 97 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (2015 елның 14 августындагы 120 номерлы, 2015 елның 29 октябрендәге 13 номерлы, 2018 елның 24 апрелендәге 93 номерлы, 2018 елның 15ноябрендәге 116 номерлы, 2018 елның 24 декабрендәге 121 номерлы, 2019 елның 24 июнендәге 139 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендэге 153 номерлы карарлар редакциясендә) 3.2 пунктындагы бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче салым органына салым ташламасы бирү турында гариза бирмәгән яисә салым ташламасын кулланудан баш тарту турында хәбәр итмәгән очракта, салым ташламасы Россия Федерациясе Салым кодексы һәм салым түләүченең салым ташламасына хокукы барлыкка килгән салым чорыннан башлап салым органы тарафыннан алынган белешмәләр нигезендә бирелә."

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда

түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының Интернет- мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырырга: http://aznakayevo.tatar.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис С.З.Зиннурова